**МЕЖРЕГИОНАЛЬНАЯ ОЛИМПИАДА ШКОЛЬНИКОВ «ЮНИОР»**
**ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**
**ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНЫЙ ЭТАП**
**2023-2024 учебный год**
**5 КЛАСС**

**Таблица ответов**

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| а | X | | | | | X | | X | | | | | X | | | X | X | X | | |
| ә | | | | X | | | X | | X | | | | | | | | | | X | |
| б | | X | X | | | | | | | X | X | | | X | X | | | | | |
| в | | | | | X | | | | | | | X | | | | | | | | X |
| | ***задания по 1 баллу*** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

1.Фонетика нәрсәне өйрәнә? (1 балл)
**а) сөйләм авазларын;**
ә) сүз ясалышын;
б) сүзләрнең дөрес язылышын;
в) сүзләрнең мәгънәсен.

2. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләр рәтен билгеләгез. (1 балл)
а) кечкенә, чибәр, килешү;
ә) былбыл, чыпчык, карга;
**б) имтихан, китап, миңа;**
в) бәхет, канат, матур.

3. **<u>Искерә</u>** сүзенең антонимын билгеләгез. (1 балл)
а) зурая;
ә) ис керә;
**б) яңара;**
в) ис чыга.

4. Лексик мәгънәләре төрле, аваз составы бер үк булган сүзләр –
(1 балл)
а) синонимнар;
**ә) омонимнар;**
б) антонимнар;
в) фразеологизмнар.

5. Мәкальне дәвам итегез. (1 балл)
Егет кешегә җитмеш төрле...
а) машина белү дә аз;
ә) эш кирәк;
б) спорт костюмы кирәк;
**в) һөнәр дә аз.**

6. Бер мәгънәле кисәктән торган сүзләр рәтен билгеләгез. (1 балл)
**а) балан, песнәк, колын;**
ә) баллы, кошчык, тизрәк;
б) шаулы, шатлык, дускай;
в) җиләк-җимеш, аксыл, эшли.

7. Тамырдаш сүзләр арасына ялгыш кергән сүзе булган рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) каен, каенлык, каендай;
**ә) кыр, кырчылык, кырау;**
б) кызык, кызыклы, кызыксыну;
в) җыр, җырлый, җырчы.

8. III зат, берлек санда, юнәлеш килешендә булган алмашлыкны табыгыз. (1 балл)
**а) сиңа;**
ә) миңа;
б) аңа;
в) аның.

9. Сыйфаты булган җөмләне билгеләгез. (1 балл)
а) Боз һәм кар эреде. (Г. Тукай)
**ә) Иртәнге таң нурыннан уянды ромашкалар. (М. Җәлил)**
б) Менә көрәш башланды. (М. Галәү)
в) Бу диңгезнең зурлыгы искитәрлек. (Ф. Әмирхан)

10. Бәйлек сүзләрдән торган рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) өчен, белән, таба;
ә) ләкин, әгәр, чөнки;
**б) янында, каршына, астыннан;**
в) апасыннан, китабына, бакчасында.

11. Менә бераздан карт имән уянды (Г. Сабитов) җөмләсендә рәвеш кайсы сүз төркемен ачыклап килгән? (1 балл)
а) исемне;
ә) сыйфатны;
**б) фигыльне;**
в) рәвешне.

12. Рәвешнең төп синтаксик функциясе –(1 балл)
а) хәбәр булу;
ә) аергыч булу;
б) тәмамлык булу;
**в) хәл булу.**

13. Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа азга гына.
Бөтенләйгә түгел, вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагына
(Р. Миңнуллин)
җөмләсендә рәвешләр –(1 балл)
а) биреп торчы, түгел;
**ә) бөтенләйгә, вакытлыча;**
б) җитәрлек, миңа;
в) асыл, азагыма.

14. Халык чишмәләргә матур исемнәр дә кушкан: Ак чишмә, Татлы чишмә, Ишфалы чишмә (Г. Бәширов) җөмләсендә кайсы сүз ия? (1 балл)
а) исемнәр;
ә) чишмә;
**б) халык;**
в) матур.

15. Кичә кичке якта яңгыр яуган иде (Ә. Хасанов) җөмләсендә ничә җөмлә кисәге бар? (1 балл)
а) 6;
ә) 5;
**б) 4;**
в) 3.

16. Җыйнак җөмләне билгеләгез. (1 балл)
**а) Инсаф укый.**
ә) Язга таба көннәр озыная.
б) Энҗе чәчәк хуш исле була.
в) Бүген көн болытлы.

17. Автобиографик әсәр –
**а) Язучының үз тормышы, үткәне турында язган әсәре.**
ә) экияткә нигезләнеп, драма әсәре формасында язылган арадаш (смешанный) жанр төре;
б) сөйләп бирүгә, хикәяләүгә нигезләнгән, вакыйгага корылган әдәби әсәр;
в)драматик әсәр;

18. Г.Тукайның туган авылы? (1 балл)
**а)Кушлавыч**
ә)Казан
б)Кырлай
в)Өчиле

19. Габдулла Тукайның шигырен күрсәт.
а) “Туган як”
**ә) “Туган авыл”**
б) “Туган көн”
в) “Туган җир”

20. Муса Җәлил ничәнче елда туган?
а)1886
ә)1994
б)1946
**в)1906**

***II. -мак*** иҗегенә тәмамланган сүзләр килеп чыгарлык итеп, шакмакларга хәрефләр языгыз. **(10 балл)**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **м** | **а** | **к** |
| | | | **м** | **а** | **к** |
| | | | **м** | **а** | **к** |
| | | | **м** | **а** | **к** |
| | | | **м** | **а** | **к** |
| | | | **м** | **а** | **к** |
| | | | **м** | **а** | **к** |
| | | | **м** | **а** | **к** |
| | | | **м** | **а** | **к** |
| | | | **м** | **а** | **к** |

III. Атна исемнәрен татарча яз. (7 балл)
Понедельник — Дүшәмбе
Вторник — Сишәмбе
Среда — Чәршәмбе
Четверг — Пәнҗешәмбе
Пятница — Җомга
Суббота — Шимбә
Воскресенье — Якшәмбе

IV. Иҗади бирем
Ял көнегезне сурәтләп, кечкенә генә сочинение төзеп языгыз. (10 җөмлә). (10 балл)
Иҗади биремне бәяләү критерийлары:
1. Язма эшнең эчтәлеге темага туры килә – 2 балл
Язма эшнең стуктур элементлары (кереш өлеше, төп өлеше, нәтиҗә) төгәл күрсәтелгән - 3 балл
2. Орфографик хаталар 1-2 күп түгел- 2 балл
3. Пунктуацион хаталар 1-2 күп түгел – 1 балл
4. Логик хаталар юк- 1 балл
5. Фактик хаталар юк – 1 балл